КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 февраль г.Казань № 81

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче; 2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче; 2020 ел, 12 март, 187 нче, 2020 ел, 21 сентябрь, 850 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда ел саен Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясен түләүгә акча бирүне күздә тотарга:

«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча - 2021 елдан башлап ике елга бер тапкыр 200,0 мең сум күләмендә;

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы» ведомство буенча 2022 елдан башлап ике елга бер тапкыр 200,0 мең сум күләмендә.»;

әлеге карар белән расланган Г.Р. Державин исемендәге Республика премиясе турында нигезләмәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе (алга таба - премия) язучыларга әдәбият (поэзия, проза, әдәби тәрҗемә, публицистика, әдәби тәнкыйть)

өлкәсендә аеруча әһәмиятле әсәрләр өчен бирелә, алар рус һәм (яисә) татар телләрендә, шул исәптән Г.Р. Державин иҗатын популярлаштыручы киң җәмәгатьчелек танылуы алган, һәм юристларга фәнни тикшеренүләр (монографияләр) һәм юриспруденция өлкәсендә якланган диссертацияләр өчен бирелә. Күрсәтелгән эшләр (алга таба - эшләр) соңгы биш ел дәвамында, әмма премияне алуга тәкъдим ителгәнче бер елдан да соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Премия елга бер тапкыр 200,0 мең сум күләмендә бер премия күләмендә бирелә: әдәбият өлкәсендә 2021 елдан башлап ике елга бер тапкыр һәм юриспруденция өлкәсендә 2022 елдан башлап ике елга бер тапкыр.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Премия Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясе комитеты (алга таба - Комитет) рәисе тарафыннан ел саен, кагыйдә буларак, 14 июльдә - Г.Р.Державинның туган көнендә тапшырыла.»;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Премия кабат бирелми.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Премия алуга материаллар 23 майга кадәр карау өчен Комитетка түбәндәге адреслар буенча тапшырыла: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт (әдәбият өлкәсендә эшләр өчен) һәм 420111, Казан шәһәре, Кремль урамы, 16 йорт (юриспруденция өлкәсендә эшләр өчен).»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Оешма эшен күрсәтү турында гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла:

эшне күрсәтү турында оешманың коллегиаль карары (коллегия беркетмәсе, утырыш, сәнгать һәм гыйльми совет, хезмәт коллективы җыелышлары);

шәхси белешмәләрне һәм иҗади характеристиканы үз эченә алган эзләүче анкетасы, авторның ике фотографиясе (6 × 9 см);

тәкъдим ителгән эшнең кыскача аннотациясе;

авторның (авторлар коллективының) эшне булдыруга керткән өлешен характерлаучы материал;

тиешле өлкәдә белгечнең тышкы рецензиясе (әдәбият һәм юриспруденция);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча гражданның бурычы булмавы турында белешмә;

Барлык материаллар да премия алуга эш тәкъдим итүче оешма тарафыннан таныклана. Бер оешма тарафыннан берничә эш күрсәтелгән очракта, аларның һәркайсына аерым гариза төзелә.»;

III бүлек исемендә «премияне алуга эшләрне сайлап алу» сүзләрен «конкурста җиңүчеләрне билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

беренче абзацта «премияне алуга эшләрне сайлап алу» сүзләрен «конкурста җиңүчеләрне билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «яңа» сүзеннән соң «һәм югары фәнни дәрәҗә» сүзләрен өстәргә;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Комитетка конкурс эшләрен кабул итү һәм карау (бәяләү), сайлап алу буенча бурычлар йөкләнә.

Конкурсны игълан итү һәм уздыру, шулай ук бүләкләү документларын рәсмиләштерү һәм тапшыру, премияләрне түләү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (әдәбият өлкәсендә) һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (юриспруденция өлкәсендә) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Премия бирү турындагы карар әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән конкурс җиңүчеләрен билгеләү критерийлары нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән Комитет утырышында кабул ителә.

Тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү һәм оештыру өчен Комитет әгъзаларыннан өч кеше составында хисап комиссиясе сайлана.

Комитет әгъзасы шәхсән үзе катнашырга мөмкин булмаса, читтән торып тавыш бирү хокукына ия, конкурс эшләрен карау (бәяләү) комитетына мөһерләнгән рәвештә җибәреп.

Әгәр Комитет әгъзаларының тавыш бирү нәтиҗәләре тигез санда баллар тәшкил итсә, Комитет рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия.

Кабул ителгән карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Конкурста җиңүчеләр турында мәгълүмат беркетмәгә имза салынганнан соң биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының (әдәбият өлкәсендә) (http://mincult.tatarstan.ru) һәм (яисә) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының (юриспруденция өлкәсендә) (http://minjust.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырыла.»;

күрсәтелгән карар белән расланган Г.Р.Державин исемендәге Республика премиясе комитеты составында:

Комитет составыннан Р.Т.Борһановны чыгарырга;

Комитет составына Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Хәдиуллин Илсур Гәрәй улын кертергә;

Әюпова Ирина Хафизҗан кызы вазыйфасы атамасына «, Комитет рәисе урынбасары» сүзләрен өстәргә;

Заһидуллин Рөстәм Илдус улы вазыйфасы атамасына «, Комитет рәисе урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

Зарипов Илдус Фатыйх улы вазыйфасы атамасында «башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен «башлык» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин